12+

DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы | **10** март, **2016** ел | № 1 (146)

Г.Тукай ... **2**
Театр ... **3**
Шәхес ... **4-5**
Татар дөньясы ... **6**
Спорт ... **7**
Милли хәзинә ... **8**



Фәнүзә Нуриева

# Гүзәл затның асылы

Хатыннарда үзләрен сөйдерүче 3 төрле сыйфат бар: матурлык вә гүзәллек; гакыл вә тәрбия; зирәклек вә нәзакәт.

Ризаэддин Фәхретдин.

THE WORLD UNIVERSITY RANKINGS

КФУ Times Higher Education (Британия) тарафыннан төзелгән «Аурупаның иң яхшы 200 университеты» рейтингында 151-160 диапазонында үзенең лаеклы урынын тапты. Анда Россиянең 5 вузы кергән, КФУ – 4 нчесе, ә «5-100» проектында катнашучы уку йортлары арасында 3 нче урында исәпләнә.



Быелгы кышның соңгы көне КФУның татар журналистикасы кафедрасы студентлары өчен «Сөембикә» журналы баш мөхәррире Ләйсән Юнысова һәм аның урынбасары **Гөлнур Сафиуллина** белән очрашу көне буларак истә калачак. Аралашу кайчак кискен тонда барса да, журнал хезмәткәрләре үсеп килүче журналистлар буыныннан язмалар көтүен белдерде.



Финляндиянең Татар мәдәни җәмгыяте татарны өйрәнү белән шөгыльләнүче студентлар өчен 1 мең евро күләмендә семестрлык стипендия бәйгесе игълан итә. Стипендиягә дәгъва кылучылар татарны өйрәнүнең төрле өлкәләренә караган тикшеренү проектлары тәкъдим итәргә тиеш. Тулырак мәгълүмат ftatar.ru сайтында.

• **Редактор сүзе**

## ЯЗ – ЯҢАЛЫК ИЛЧЕСЕ



*Мин гомер буе табигать күренешләрен күзәтергә яратам. Бер фасылның икенчесен алыштыруы, табигатьнең яшәрүе, картаюы – үзе зур бер могҗиза… Табигатьтә бөтен нәрсәгә җавап табарга була. Ул сине һич кенә дә алдамый: төннән соң көн килә, кыштан соң – яз…*

*Яз айлары керүгә, табигатьтәге үзгәрешләр көннән-көн күбрәк күзгә ташлана башлый. Менә без дә, язга ияреп, газетабызга үзгәрешләр кертергә булдык. Кызганыч, төрле сәбәпләр аркасында, «Darelfønyn» газетасы кәгазь вариантында яңа елдан бирле чыкмады, әмма без КФУ сайтында, социаль челтәрләрдә гел сезнең белән элемтәләрне өзмәскә тырыштык, яңалыкларны даими шунда элеп бардык. Язмыш кануны шундый: матбугат чаралары заман белән бер ритмда атларга, яңалыкка омтылырга тиеш. «Darelfønyn»ебез дә хәзер үзгәрде, сәхифәләр саны артты, сайтыбыз (darelfonyn.kpfu.ru) яңарды. Без уку йорты яңалыклары һәм актив студент тормышыннан тыш, Идел буе регионнарында, республика һәм шәһәр тормышындагы яңалыкларны, туган тел, гореф-гадәт, Татарстаныбызда һәм Идел буе төбәгендә яшәүче халыкларның проблемаларын да яктыртырга тырышабыз. Милли тормышның үзәгендә кайнаучы, татар ихтыяҗын кайгыртып яшәүче һәм эшләүче милләттәшләребез, шул исәптән яшьләребез дә, шөкер, шактый күп. Шундыйларга мөрәҗәгать итәбез: безгә языгыз!*

*Уку йортыбыз сокландыгыч адымнар белән алга бара. Күпләр өчен өметләр, ышанычлар, ниятләр нәкъ менә Казан федераль университеты белән бәйле. Яз безнең тормышыбызга, университетыбызга яңа омтылыш, көч, дәрт, иҗади уңышлар алып килсен. Ходай теләкләребезне тормышка ашырырга ярдәм итсен, рәхименнән һәм шәфкатеннән ташламасын! Бергә булыйк!*

Иң изге теләкләр белән,
**Ләйлә Сабирова.**




## «ТУКАЙЛЫ ХАЛЫК БЕЗ!»

21 нче мартның Халыкара шигърият көне буларак билгеләнүе юкка түгел. Нәкъ яз фасылы кеше күңелендә хисләр буранын уятып җибәрә, иҗатка, матурлыкка орлык сала. Ә безнең өчен һәр яз Тукайны искә төшерә, һәр яз бездә Тукайлы… Быел татар халкы һәм, гомумән, бөтен төрки дөнья бөек шагыйребезнең 130 еллыгын бәйрәм итәчәк. «Darelfønyn» газетасы да бу агымнан читтә түгел. Халык шагыйренең исемен мәңгеләштерү максатыннан, «Тукайлы халык без!» исеме белән даими сәхифә ачып җибәрәбез. Һәр санда олуг язучының шәхесе, аның шигърияте белән бәйле язмалар урын алачак. Тукай исеме йөрәкләрдә яңа шигырь булып яңгырасын!

### 2016 ЕЛДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ 13 ШӘХЕС ҺӘМ БЕР ИҖАДИ ТӨРКЕМ ДӘГЪВА КЫЛА. АЛАР ТҮБӘНДӘГЕЛӘР:

**Равил Айдаров** («XIX – XX гасырларда Казанның агач йортлары» тарихи-архитектура монографиясе өчен); **Ренат Әюпов** (Габдулла Тукай иҗатына һәм тормышына багышлап куелган спектакльләре өчен); **Фәүзия Бәйрәмова** («Күчем хан» тарихи романы, «Кырык сырт: романнар» китаплары өчен); **Флера Гыйззәтуллина** («Яңу дәверләрендә: поэма-трилогия», «Башкаемда – дөнья исәпләре» китаплары өчен); **Шәмсия Җиһангирова** («Илаһият: шигырьләр», «Бәхетең үз кулыңда: җырлар» китаплары өчен); **Нәҗип Нәккаш** (Исмәгыйлев) (шамаилләр циклы, «Ярдәм» һәм Түбән Кама районының Шәңгәлче мәчетләрен бизәгән өчен); **Газинур Морат** («Кош хокукы: шигырьләр һәм поэмалар» китабы өчен); **Вакыйф Нуруллин** (ике томлык «Сайланма әсәрләр»е өчен); **Гөлзадә Сафиуллина** (күп еллар дәвамында мәдәнияттәге хезмәтләре, халыкара «Сөембикә варислары» бәйгесе, «Үлемсез ил җыры», «Илаһи моң» фестивальләре һәм «Әй, киң төрки даласы» концерт программасы өчен); **Җәүдәт Сөләйман** («Сүтелә йомгак…: шигырьләр, поэмалар» китабы өчен); **Айдар Хәлим** («Өч аяклы ат», «Кыйбла», «Казыктагы тальян» повестьлары, «Татар вакыты» романы өчен); **Альберт Хәсәнов** («Җанбәт җәвере», «Данәгөл», «ТанДим», «Бүре баласы Чатан» китаплары өчен); **Зиннур Хөснияр** («Кичү» китабы өчен); **«Болгар цивилизациясе. Мең елга сузылган юл»** дип аталган сәнгати экспозициягә әзерләүчеләр төркеме: **Илья Артамонов** (рәссам-проектлаучы), **Александр Леухин** (рәссам-проектлаучы), **Фәрит Вәлиуллин** (рәссам – монументалист), **Рәшид Шиһабетдинов** (рәссам-монументалист), **Игорь Щетинин** (рәссам-монументалист), **Айрат Ситдыйков** (А.Халиков исемендәге археология институты директоры), **Рамил Хәйретдинов** (Казан федераль университетының Халыкара багланышлар, тарих, көнчыгышны өйрәнү институты директоры), **Дмитрий Бугров** (археолог).

# ВГИКтан БАШ ТАРТЫП, КФУга

**Миләүшә НИГЪМӘТУЛЛИНА,** Филология
һәм мәдәниятара багланышлар институты

27 нче МАРТ БӨТЕН ДӨНЬЯ КҮЛӘМЕНДӘ ХАЛЫКАРА ТЕАТР КӨНЕ БУЛАРАК БИЛГЕЛӘП ҮТЕЛӘ. КАЙБЕР ФИКЕР ИЯЛӘРЕ «ДӨНЬЯ УЛ – ТЕАТР, Ә БЕЗ – АКТЕРЛАР», – ДИЯРГӘ ЯРАТА. ТОРМЫШЛАРЫН ТЕАТР ДӨНЬЯСЫ БЕЛӘН БӘЙЛӘГӘН, СӘХНӘДӘН БАШКА ЯШИ АЛМАГАН КЕШЕЛӘР ӨЧЕН ТЕАТР УЛ НӘРСӘ? БУ ТУРЫДА БЕЗ КФУның «МИЗГЕЛ» ЯШЬЛӘР ТЕАТРЫ АКТЕРЫ **НИЯЗ ВӘЛИУЛЛИН** БЕЛӘН СӨЙЛӘШЕРГӘ БУЛДЫК.



**– Нияз, театр дөньясына ничек килеп кердең?**

- 11 нче сыйныф ахырында Мәскәүгә ВГИКка керергә әзерләнгән идем. Ләкин, якыннарым киңәшләренә колак салып, бу фикердән баш тартырга туры килде. Төпле белем, яхшы эш урыны булсын дип, КФУның инглиз-испан телләре бүлегенә укырга кердем. Шулай да театр турындагы хыяллар тынычлык бирмәде, күңел гел нәрсәдер эзләде һәм тапты. Үзебезнең уку йортында ук театр эшләп килгәнлеген белдем дә, үземне сынап карарга булдым.

*Театр ул – үзе бер бөтенләй башка дөнья. Аңа бер бирелдеңме, тиз генә аерылам димә инде син.*
(М.Җаббаров)

**- Беренче мәртәбә сәхнәгә чыгуыңны хәтерлисеңме?**

- Балалар бакчасында чакта, мине һәм тагын өч баланы Фәнис Яруллинның юбилеенда чыгыш ясаттылар. Фәнис ага үзе дә бар иде. Шуннан башлангандыр инде. Ә беренче мәртәбә зур сәхнәдә уйнаганда, миңа 16 яшь иде. Баулының драма театрында уйный башладым.

**- Нияз, син пародияләр дә куясың бит әле. Пародия спектакльдә роль уйнаудан нәрсә белән аерыла?**

- Рольне безгә автор «бүләк итә», тик син аны үзеңчә күрәсең, тоемлыйсың. Режиссер рөхсәт итсә, бераз үзгәрешләр дә кертә аласың. Ә пародиядә берни үзгәртергә ярамый, пародия ул – кабатлау. Мәсәлән, шул ук Жириновский, Путинның сөйләшү рәвеше, мимика, хәрәкәтләренә игътибар итәргә кирәк.

**- Спектакль вакытында иң авыры нәрсә?**

- Сәхнәгә чыгу, беренче адым ясау авыр. Ә бер чыксаң һәм героеңны тоемласаң, барлык борчулар онытыла.

**- Ниязны бер читкә куеп, герой образына керү ничегрәк үтә?**

- Режиссер Марсель абый Җаббаров белән бергә эшлибез. Иң беренче, рольне бирер алдыннан, актер белән геройны чагыштыра ул. Аннары геройның нәрсә хис иткәнен, характерын аңлата. Ә калганы – вакыт һәм тырышлык эше.

**- Спектакльдән соң герой кая китә?**

- Беркая да китми, минем эчемдә яшәвен дәвам итә. Алай гына да түгел, герой мине үзгәртә башлый. Мәсәлән, «Кыр казлары артыннан» спектакленнән соң, миндә байлык, акчага мөнәсәбәт кисәк үзгәрде.

**- Илһам чыганагың бармы?**

- Кемдер табигать, музыка белән илһамлана. Минем өчен сәхнә үзе – илһам чыганагы.

**- Нинди роль уйнамас идең?**

- Елак кешеләрне яратмыйм. Шуңа күрә бернинди уңай хис-кичерешләр булмаган, гел елауга кайтып калган спектакльдә елак кешене уйнамас идем, мөгаен.

**- Тәнкыйтьне кабул итә беләсеңме?**

- Әйе, шуңа өстәп, мин үземне үзем еш тәнкыйтьлим. Мәсәлән, «Соң инде шул» спектаклендәге капитан ролен башкаруым ошамады, әле дә ошамый.

**- Укуыңны калдырып торып, кинога төшәргә тәкъдим итсәләр, нишләр идең?**

- «Ирония судьбы» киносын кабат төшерүләрен һәм миңа Ипполит ролен бирүләрен сорар идем (*көлә*).

**- Театр һәм укудан кала нәрсә белән шөгыльләнәсең?**

- КФУда Икътисад министрлыгы ярдәмендә «Фабрика предпринимательства» проекты эшләп килә. Шунда катнашам, эшмәкәр эшчәнлеге серләренә төшенеп ятыш.

«Мизгел» яшьләр театры

1996 нчы елдан эшләп килә

21 спектакль куелган

15 артист исәпләнә

4 спектакль «Яңа гасыр» фондында

• Шәхес

# «ҺӘР СТУДЕНТЫМА ТИРӘН ХӨРМӘТ БЕЛӘН КАРЫЙМ»

**Рузилә ӘМИРОВА, Гүзәл ЗАКИРОВА**

КЫШКЫ САЛКЫННАР УЗЫП, КОЯШ ҖӘЙГӘ ТАБА БОРЫЛГАН ЯМЬЛЕ КӨННӘРДӘ КҮРЕНЕКЛЕ ТЕЛ БЕЛГЕЧЕ, ФИЛОЛОГИЯ ФӘННӘРЕ ДОКТОРЫ, ПРОФЕССОР ФӘНҮЗӘ ШӘКҮР КЫЗЫ НУРИЕВАГА 60 ЯШЬ ТУЛДЫ. ӘЛЕГЕ ЮБИЛЕЙ УҢАЕННАН, БЕЗ ФӘНҮЗӘ АПАГА ҮЗЕБЕЗНЕ КЫЗЫКСЫНДЫРГАН СОРАУЛАРНЫ БИРЕРГӘ БУЛДЫК.

**– Иң беренче чиратта Сез кем – укытучымы, галимә, хатын, әниме?**

- Укытучы булу баланы яратуга бәйле, һәр укыткан студентыма тирән хөрмәт, ышаныч белән карыйм. Мин үземнең гаиләмне, якыннарымны яратып һәм аларның да ярату җылысын тоеп яшим. Галим төшенчәсен тормышын, яшәешен бары фәнгә багышлаган күренекле шәхесләргә карата гына кулланам.

**- Фәнгә ничек килдегез?**

- Казан университеты тарих-филология факультетының татар теле бүлегенә укырга керүем Кызылъяр урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фәһимә Сәгыйтовнага бәйле. Мин аның дәресләрен шулкадәр көтеп ала идем, күп укый идем. Укытучымның әдәби сөйләме, матур аһәңле тавышы, дәресне алып баруы шулкадәр ошый иде. Фәһимә апа кебек татар теле һәм әдәбияты укытучысы булу теләге мине Казанга алып килде. Университетка килгәч, морфология курсыннан безнең төркемдә лекция алып барган профессор, факультетыбызның деканы Диләрә Гарифовна Тумашева үзендә курс эше язарга тәкъдим итте. Беренче фәнни адымнарым шулай башланды. Танылган галим җитәкчелегендә татар теленең гаҗәеп бай, үзенчәлекле фигыль сүз төркемен өйрәнүгә керештем. Аспирантурада искиткеч кешелекле, зыялы, дөньякүләм танылган галим, Мәскәү шәһәрендә СССР Фәннәр академиясе Тел белеме институтының Төрки һәм монгол телләре бүлеге җитәкчесе Әдһәм Рәхим улы Тенишев һәм аның шәкерте Фәрид Хәкимҗанов җитәкчелегендә уку бәхетен кичердем.



*Нуриева Фәнүзә Шәкүр кызы Баулы районы Иске Чүте авылында 1956 елның 8 нче март көнендә туган.*

**- Балачакта без фишкалар, покемоннар белән уйный идек, компьютер, телефоннан аерылмадык, ә менә сезнең балачак ничек узды?**

- Мәктәптә укыганда, сәхнәдән шигырь сөйли идем, гимнастик күнегүләр күрсәтә идек. Студент елларында да бер буш вакыт булмады, төрле түгәрәкләргә йөрдек, татар хорында җырладык, авылларга концерт белән чыга идек. Китапны да күп укыдык. Кино-театрларга еш йөри идек. Хәзер дә аптырыйм, каян вакыт тапканбыз, каян акча җиткергәнбез. Менә компьютер уеннары булмады булуын. Хәзер оныклар белән уйныйбыз. Компьютер серләрен шактый соң үзләштерергә туры килде.

**- Сез беренче тапкыр кайчан гашыйк булдыгыз?**

- Мәктәптә укыганда дуслык булгандыр. Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ындагы Галия... Мин бик бирелеп, дулкынланып укый идем әлеге әсәрне. Әсәрдәгечә, артист егеткә гашыйк булдым. Драмтүгәрәкнең режиссеры булган Гаптрәүф Салих улы белән 34 ел гомер кичерәбез, ике ул үстердек: Әнәс һәм Әннур. Аларның инде үз гаиләләре. Аллага шөкер, дүрт оныгыбыз үсеп килә.

**- Тормышта сезнең өчен иң зур авторитет кем?**

- Әнием Рәисә Хәйретдин кызы. Кечкенә генә уңышыма зур итеп сөенә иде, күп гамәлләрем әниемне шатландыру өчен эшләнде.

**- Студент чорында нәрсәләр эшләргә өлгереп калырга кирәк?**

- Максатыңа бәйле мөмкинлекләр бик зур хәзер. Мин чит телләр өйрәнүгә басым ясар идем.

**- Ялларыгызны кайда, ничек итеп үткәрәсез?**

- Ял вакытын китап укып, язу артында үткәрәм, лекция өчен яңа материал туплау, тапшырырга тиешле монографияне эшкәртү һәм башкалар. Гаиләм, балаларым, оныкларым өчен һәрчак вакыт табам. Аларны тәмле



ризыклар белән сыйлыйм, төрле кызыклы чараларга бергәләп йөрибез. Авылда булабыз, чит илләргә дә барып кайтыла. Музейга, кинотеатрларга да, бик еш булмаса да, барырга тырышабыз.

**- Яраткан әдәби әсәрләрегез, аеруча яратып укыган авторларыгыз бармы?**

Мәхмүд Болгариның 1357 нче елда язылган «Нәһҗел Фәрадис»ы. Буш вакытларымда Әмирхан Еники, якташым Фәнис Яруллин, Пауло Коэльо әсәрләрен яратып укыйм.

**- Нинди фильмнар карыйсыз?**

- Соңгы караган фильмнар — мавыктыргыч маҗараларга корылган «Аватар», «Пираты Карибского моря». Джонни Депп башкарган пират образы күңелгә ятышлы булды. Хезмәттәшем Халисә Ширмән әсәрләренә нигезләнеп куелган татар сериалларын яратып карыйм. Март аенда ирем Гаптрәүф Салихович белән Татарстанда төшерелгән «Семейные хлопоты» фильмына барырга җыенабыз.

**- Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Фәнүзә Шәкүровна! Сезгә киләчәктә дә уңышлар, саулык-сәламәтлек, җан тынычлыгы һәм яшь күңелле булып калуыгызны телибез!**

*Үтелгән тормыш юлым – табышларым, югалтулар, уңышларым миңа язылган. Яшәвемнән, тормышымнан, шөкер, канәгать.*

## Фәнүзә Шәкүровна хакында аның студентлары

*Ришат, 3 нче курс студенты:*



**Фәнүзә Шәкүровна** — искиткеч белемле мөгаллимәбез. Тюркология фәненнән аның лекцияләрен тыңлаганым бар. Әлеге олуг шәхеснең үзенчәлекле фикерләре, аһәңле сөйләме, ачык тавышы һәр кешене таң калдыра. Шулай ук Фәнүзә Шәкүр кызы – олы йөрәкле, изге күңелле, искиткеч әңгәмәдәш тә. Аңа алга таба да иҗади уңышлар, саулык – сәламәтлек телим.

*Илсөя, 4 нче курс студенты:*



**Фәнүзә Шәкүровнаны** мин беренче курстан бирле беләм. Ул затлы, зыялы, безгә карата игътибарлы булуы белән үзенә җәлеп итте. Фәнүзә Шәкүровна шулай ук безне җаваплы булырга, алган белемнәрне системага салырга, тарихыбызны белергә, максатчан булырга өнди. Мин аның оптимизмына, һәрвакыт яшь, көләч булуына чын күңелдән сокланам.

*Айгөл, аспирант:*



**Фәнүзә Шәкүровна** турында бары тик яхшы истәлекләр генә миндә. Университетта уку дәвамында һәрчак безнең белән, студентлар арасында иде. Фәнүзә апа – иң белемле, тәҗрибәле, таләпчән һәм хөрмәткә лаеклы укытучыларның берсе. Аның дәресләрен гел көтеп ала идек. Фәнүзә Шәкүровна белем биреп кенә калмады, бездә зәвык, тормыш өчен мөһим булган сыйфатлар тәрбияләүгә зур игътибар бирде.



• Татар дөньясы

# ЭЧКЕ «МИН» БЕЛӘН ДУС БУЛ

**Айгөл АБДРАХМАНОВА**

ИСКӘРГӘНЕГЕЗ БАРМЫ: СОВЕТ ФИЛЬМНАРЫНДА УҢГАН КЫЗЛАРГА «СПОРТСМЕНКА, КОМСОМОЛКА И ПРОСТО КРАСАВИЦА» ДИЛӘР. МОНДЫЙ КЫЗЛАР КИНОДА ГЫНА ТҮГЕЛ, ТОРМЫШТА ДА БАР.

Шундыйларның берсе – КФУның Социаль фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты студенты, спортсменка, староста һәм «Мисс-Казан» титулы иясе Софья Мостафина.

**- Софья, университет һәм матурлык бәйгеләреннән тыш, нәрсә белән шөгыльләнәсең?**

- Безнең гаиләдә белем алуга, фәнгә зур игътибар бирелә. Шуңа күрә үзлектән Мәрҗани мәчете, Фукс йорты һәм Юнысовлар гаиләсе тарихын өйрәнергә, архивларда утырырга һәм яңа мәгълүмат табарга тырышам. Кызыклы шәхес булып җитлегү өчен, төрле яктан үзеңне үстерергә кирәк дип саныйм. Шуны истә тотып, пешекче һөнәрен үзләштерәм, күптән түгел генә визажист-стилистка укып чыктым.

**- Казан гүзәленең студент тормышы ничек бара?**

- «Мисс-Татарстан» бәйгесендә катнашканчы да, хәзер дә университет тормышында кайнап яшим. Дәресләр, укудан тыш, төркем старостасы вазыйфасын да башкарам. Гомумән, студентлык чорын мөмкин кадәр актив уздырырга кирәк дип саныйм.

**- «Мисс-Татарстан» бәйгесенә ничек барып әләктең?**

- Иптәш кызларым тырышлыгы белән. Алар «Краса студенчества» бәйгесендә катнашырга тәкъдим иттеләр. Нәтиҗәдә «Первая краса студенчества» исеменә лаек булдым. Бу бәйгедән соң миңа «Мисс-Татарстан» бәйгесенә дә юллар ачылды.

**- Күптән түгел генә яз бәйрәмнәре узды. КФУның гүзәл затларына нәрсәләр теләр идең?**

- Гадәттә, бәйрәмнәрдә бәхет телиләр. Шуңа өстәп, эчке «мин» белән дуслык теләр идем. Дөньядагы һәр хатын-кыз матур һәм сәләтле. Кадерле гүзәл затлар, үз-үзегезне яратыгыз һәм хөрмәт итегез!

# «АКЫЛ ФАБРИКАСЫ» – ӘСТЕРХАНДА

**Гүзәлия ГЫЙНИЯТУЛЛИНА**

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ ФОРУМЫ 5-6 нчы МАРТ КӨННӘРЕНДӘ ӘСТЕРХАН ШӘҺӘРЕНДӘ «АКЫЛ ФАБРИКАСЫ» БЕЛЕМ БИРУ ҺӘМ ПРОЕКТЛАР МӘКТӘБЕ УЗДЫРЫП КАЙТТЫ.

Бу юлы чара «Этномәдәни проектларның менеджменты» темасына багышланган иде.

Ике көн барган әлеге чарада Саратов, Волгоград, Волжск, Армавир, Ростов, Краснодар, Атырау (Казахстан) шәһәрләре, Дагстан, Карачай-Чиркас Республикаларыннан килгән иң алдынгы татар яшьләре катнашты.

«Акыл фабрикасы» мәктәбенең ахырында командалар мәдәниятне үстерүгә, телне саклауга, тарих һәм туризм темасына багышланган үзләренең проектларын якладылар. Алар арасында түбәндәге кызыклы проектлар тәкъдим ителде:

**«Яңа ефәк юлы».** Әлеге проект сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга, Әстерханда яшәүче татарларның мәдәниятен, тарихын өйрәнүгә багышланган. Проект Әстерхан өлкәсенең 16 авылы буенча веломаршрут үткәрүдән гыйбарәт.

**«Хан эзләре буенча».** Проект тарих, мәдәният ягыннан белемнәр туплау максатыннан төзелгән. Проект Россиядәге берничә шәһәр буенча экскурсиядән тора.



Лилия Туктарова фотосы

**«T2T» проекты.** Дөньядагы барлык татарларны җыючы сайт төзү.

**«Әбигә авылга».** Әлеге проектның мәгънәсе — татар телен, гореф-гадәтләрне өйрәнү. Бер төркем студентларны татарлар яшәгән авылларга җибәрәләр. Ике атна дәвамында һәр студент татар гаиләсендә яшәячәк, татар атмосферасына керәчәк.

**«Живая легенда» проекты.** Әлеге проект төрле регионнар һәм илләрдә яшәүче өлкән буын вәкилләреннән җыелган информацияләр тупланган сайттан торачак.

● **Спорт**

# ҮЗЕ МАТУР, ҮЗЕ БАТЫР!

**Раил САДРЕТДИНОВ**

КФУның БУТЛЕРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ХИМИЯ ИНСТИТУТЫ 3 НЧЕ КУРС СТУДЕНТЫ АЛИНӘ ЗИННУРОВА — УНИВЕРСИТЕТЫБЫЗНЫҢ КУЛ КӨРӘШЕ БУЕНЧА ҖЫЕЛМА КОМАНДАСЫ ӘГЪЗАСЫ, БЫЕЛ ТАТАРСТАННЫҢ УКУ ЙОРТЛАРЫ КОМАНДАЛАРЫ АРАСЫНДА КУЛ КӨРӘШЕ БУЕНЧА ИКЕНЧЕ УРЫН ИЯСЕ.



«Мондый спорт төрен үз иткәч, син, һичшиксез, авыл кызы! » — дип, бар экстрасенс осталыгымны җыеп сүз башладым мин аның белән. Һәм ялгышмадым. Алинә тумышы белән Яңа Чишмә районының Адәмсә авылыннан икән. Мәктәптә өлкән сыйныфларда укыганда кызыксынып китә ул армспорт белән. Яңа гына эшкә билгеләнгән физик тәрбия укытучысының йогынтысы зур була. Ә университетыбызның беренче курсына килгәч, хыялына тугры калып, кул көрәше түгәрәген эзләп таба. Барып кына карыйм дип килсә дә, әле дә биредә — кул көрәше буенча спорт остасы Рамил Галиуллин җитәкчелегендә шөгыльләнүен дәвам итә. Монда килеп эләгүемә һич кенә дә үкенмим, дип горурланып әйтә ул. Иң беренче чиратта, Алинә тренерының үз кул астында шөгыльләнүчеләргә карата аталарча кайгыртучанлыгын билгели. «Һәр ярыш алдыннан безнең өчен борчыла, һәр уңышыбызга сөенә, уңышсызлыкларыбызга көенә. Җиңүдән соң бергә команда белән җыелып чәйләп алу — үзе бер күңелле хәл, командалык хисен арттыра», — дип бүлеште Алинә.

Яшермим, Алинә белән очрашканчы, армспорт белән җитди итеп бары егетләр генә шөгыльләнә, кызлар өчен бу кызык уен дип кенә уйлый идем. Әмма ялгышканмын. Гүзәл затлар ныграк та тартыла икән әле бу спорт төренә. «Кул көрәше дисәк тә, без бит кулларны гына чыныктырмыйбыз. Төрле физик күнегүләр ясыйбыз, йөгерәбез. Әмма төп басым — кулларга. Көчле куллар — җиңүгә бер адым», — ди кыз, армспортның файдалы яклары турында сүз кузгаткач.

Алинә фикеренчә, җиңү өчен иң мөһиме — һәрдаим шөгыльләнү, үзеңне формада тоту. Ярышка бер дә әзерләнмичә барып булмый. Моннан тыш, психологик әзерлек тә мөһим: үз-үзеңә ышаныч булу таләп ителә. «Син нинди генә көчле булсаң да, әгәр нык борчылсаң, җиңелергә мөмкинсең», — ди кыз. «Көндәшеңнең кулын тотуга, ярышның ахыры ничек бетәсен белеп булламы?» — дип кызыксынам. Төрлечә булырга мөмкин икән, һәр кешене дә алдан белеп бетереп булмый. Һәр ярыш — җаваплы адым аның өчен. Чөнки бар көчеңне, вакытыңны җаның-тәнеңне биреп яраткан шөгылеңә багышлагач, нәтиҗәсен дә күрәсе килә бит! «Әгәр залда якыннарым, дусларым була икән, үземне тынычрак хис итәм, курку хисе югала», — ди Алинә дулкынлануын җиңү турында. Якыннары башта һәр ярыш саен борчылып, ут йотып торса, хәзер ияләнә төшкәннәр инде. Алинәнең бу шөгыленә аларның да фикере һәм карашлары уңай. Алинә өчен армспорт хобби гына түгел. Зур спортка юл башы ул. Аның фикерләрен тыңлагач, уңышлары белән танышканнан соң, күңелне кытыклаган сорауны бирәм: «Ничек уйлыйсың, кызларның спортка тартылуы матурлык эталоны үзгәрүме яки сәбәп башкадамы? Ул исә бу сорауга болай дип җавап бирде: «Җитди спорт белән шөгыльләнеп тә, матур калырга мөмкин».

**«Darelfønyn» газетасының он-лайн версиясен (http://darelfonyn.kpfu.ru) укыгыз**

## ЧӘЧӘКЛӘРНЕҢ АСЫЛ БӘЙЛӘМЕ

Университетыбызда гына үткәрелә торган уникаль **«Иң яхшы уку төркеме»** дигән традицион бәйгедә Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының 4 нче курсында укучы 10.2-201нче төркем студентлары да катнаша.



## ИҢ ЯХШЫ ИГОРЬ АБЫЙ

Быел **«Сәмрух 2015»** Республикакүләм сәләтле балалар һәм яшьләр премиясе «Сәләт» берләшмәсен актив үстерүче балаларга, яшьләргә һәм укытучыларга тәүге тапкыр тапшырылды. «Иң яхшы әйдаман» номинациясендә премиягә КФУның Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты **Игорь Смирнов** лаек булды.



● **Милли хәзинә**

# Чәчәкнең милләте бармы?

**Руфинә ДУНАЕВА**



УКУ ЙОРТЫН ТӘМАМЛАП, ҺӨНӘР АЛГАН ЯШЬЛӘРЕБЕЗНЕҢ КҮБЕСЕ ХЕЗМӘТ БАЗАРЫНДА ҮЗ УРЫННАРЫН ТАБА. БЕРӘҮЛӘР МӘГАРИФ, ХАЛЫККА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ ЯКИ МӘГЪЛҮМАТИ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ӨЛКӘСЕНДӘ ЭШЛИ, ИКЕНЧЕЛӘРЕ ЭШМӘКӘРЛЕККӘ ЧУМА, Ә КЕМДЕР... ЧӘЧӘК САТА.

«Чәчәк, флористика индустриясендә яңа сүз әйтү бүгенге базар шартларында кыен. Шәһәрдә чат саен «Чәчәкләр» дип балкып торган биналар бихисап. Анда тәкъдим ителгән тауар белән халыкны гаҗәпләндереп булмый хәзер». Болай фикер йөртүчеләр ялгыша: сез әлек татарларның милли сәүдә үзәге саналган Печән базарында урнашкан «Милли» чәчәкләр студиясенә барып карагыз!

Әлеге студиянең үзенчәлеге шунда: ул – Казанда татар телендә хезмәт күрсәтә торган, шуның өстенә милли дизайн белән эшләнгән бердәнбер чәчәк салоны. Аны КФУның Сәнгать югары мәктәбен 2014 елда тәмамлаган дизайнер-флорист **Диләрә Гадиева** җитәкли. Университетта укыганда хыял булып яшәгән фикерен ул 2015 елның 6 нчы февралендә чын чәчәк студиясе ачып тормышка ашыра.

– Студияне оештыру эше тиз һәм кинәт булды. Шулай да әйтергә кирәк: миңа милли идея студент елларыннан ук якын, ул вакытта, татар мәдәниятенә хас бизәкләрне кулланып, котлау хатлары ясау белән шөгыльләндем, флористлар курсында укыдым. Казан кызы булуыма карамастан, җәйләр һәрвакыт авылда уздым. Сабантуйга дип, сөлгеяулыклар чигә идек, бөтен кул эшләрен әбием, әнием өйрәтте. Шул чордан ук сеңеп калган милли бизәкләрнең матурлык көче, – дип сөйли Диләрә.

Чыннан да, студиядә миллилек рухы хөкем сөрә. Татарча көйләр яңгырый, бүлмәне самавыр, татарча teләкләр язылган котлау хатлары бизи. Чәчәк бәйләмнәренә миллилек өстәү өчен, кызлар татар орнаментлы дизайн тасмалар кулланалар, ләкин өстенлекне татар чәчәге саналган лалә чәчәкләренә бирәләр. Кызлар диюем юкка түгел, Диләрә студиядә кыз туганы Гөлнар Фәйзрахманова белән эшли. Гомумән, бу – аларның гаилә бизнесы икән.

«Милли» чәчәкләр студиясе китереп бирү хезмәте белән дә шөгыльләнә. Аеруча читтә яшәүче татарлар өчен кулай ул. Татар мохитенә сусаган милләттәшләребез туганнарына чәчәк бәйләмнәре, котлау хатлары бүләк итүне студия хезмәткәрләренә ышанып тапшыра. «Мәскәүдән килгән кайберәүләр «Безнең шәһәрдә дә филиалыгызны ачыгыз» дип мөрәҗәгать итәләр, ләкин безгә беренче чиратта киңлеккә түгел, биеклеккә үсәргә кирәк, – дип уйлый Диләрә. – Бәлки, вакыт үтү белән, тиешле биеклеккә җитүебезне тойгач, киңәю турында уйлана башларбыз».

Флористиканы сәнгать итеп, яратып эшли яшь эшмәкәр. Бу эшчәнлеген дә бизнеска санамый ул, яраткан шөгылен башкарып, үзен һәм башкаларны сөендерүнең мәгънәле юлын тапкан. Клиентларына яңадан-яңа идеяләр тәкъдим итәр өчен, Диләрә һәрвакыт эзләнүдә. Instagram социаль челтәре аша Америка, Англия, Япония кебек илләрдә яшәүче танылган флористларның аккаунтларына язылып, аларның иҗаты белән танышып бара икән. «Шунысы кызык, – ди ул, – чәчәк бәйләмнәре халыкның менталитетын, әхлакый кыйммәтләрен, хәтта илдәге иҗтимагый, сәяси халәтне дә чагылдыра». Болай булгач, чәчәкләрнең милләте юк дип, кем әйтә ала?!









DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ

Тираж 1000

Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: Р.Р.Дунаева, А.А.Абдрахманова
Корректор - Р.Ә.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru
Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00, 09.03.2016. «КАРТИ» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание, 100.